МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.11.2024 Казан ш. № 07-108

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2021 елның 17 декабрендәге 07-129 номерлы боерыгы белән расланган Бюджет мәгълүматларының ачыклыгы дәрәҗәсе буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә мониторингны гамәлгә ашыру һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча рейтинг төзү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Б о е р ы к б и р ә м:

«Бюджет биремнәренең ачыклыгы дәрәҗәсе буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә мониторингны гамәлгә ашыру һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча рейтинг төзү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2021 елның 17 декабрендәге 07-129 номерлы боерыгы белән расланган Бюджет биремнәренең ачыклыгы дәрәҗәсе буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре мониторингын гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Әлеге тәртипкә №1 кушымтаның 1 бүлегенә түбәндәге эчтәлектәге 1.9 – 1.11 юлларын өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «1.9 | Чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль берәмлек бюджеты турында карар проектын бастырып чыгару | Әйе, бастырылган | 4 | |
| | | Юк, бастырылмаган | 0 | |
| 1.10 | Чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль берәмлек бюджеты турында карарны бастырып чыгару | Әйе, бастырылган | 4 | |
| | | Юк, бастырылмаган | 0 | |
| 1.11 | Җирле администрация тарафыннан расланган | Әйе, барлык хисап чырлары өчен бастырылган | 4 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | агымдагы финанс елының беренче кварталы, беренче яртыеллыгы, тугыз ае өчен муниципаль берәмлек бюджетын тулыландыру турында хисапны бастырып чыгару | Ике хисап чоры өчен бастырылган | 2 | |
| | | Бер хисап чоры өчен бастырылгын | 1 | |
| | | Юк, бастырылмаган | 0» ; | |

Әлеге тәртипкә №2 кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушып бирелә).

Министр Р.Р.Гайзатуллин

(Бюджет мәгълүматларының ачыклыгы дәрәҗәсе буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә мониторингны гамәлгә ашыру һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча рейтинг төзү тәртибенә №2 кушымта (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының _________ 2024 ел, № ___ боерыгы редакциясендә)

Бюджет мәгълүматларының ачыклыгы дәрәҗәсе буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә мониторингны гамәлгә ашыру өчен мәгълүматлар

_______________________________________________

(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге атамасы)

| N п/п | Күрсәткеч | Күрсәткеч мәгънщсе | Рәсми сайтка актив сылтама | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| 1. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре (алга таба – муниципаль берәмлек) бюджетларының бюджет мәгълүматлары ачыклыгын тәэмин итү өлешендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге рәсми сайтының эчтәлеге | | | | |
| 1.1 | Агымдагы финанс елына һәм план чорына муниципаль берәмлек бюджеты турында башта кабул ителгән карарны бастырып чыгару | Әйе, структуралы рәвештә бастырылган | | Структуралы дигән төшенчә, аерым файлларда (таблицалар, кушымталар, карар тексты рәвешендә), барысының да тулы яки кыскача атамаларын күрсәтеп, мәгълүматлар урнаштыруны аңлата. |
| | | Әйе, бастырылган, әмма струтуралы рәвештә түгел | | |
| | | Юк, бастырылмаган | | |
| 1.2 | Хисап финанс елында муниципаль берәмлек бюджеты үтәлеше турындагы карар проектын бастырып чыгару | Әйе, структуралы рәвештә бастырылган | | Структуралы дигән төшенчә, аерым файлларда (таблицалар, кушымталар, карар тексты рәвешендә), барысының да тулы яки кыскача атамаларын күрсәтеп, мәгълүматлар урнаштыруны аңлата. |
| | | Әйе, бастырылган, әмма струтуралы рәвештә түгел | | |
| | | Юк, бастырылмаган | | |
| 1.3 | Хисап финанс елында | Әйе, структуралы рәвештә | | Структуралы дигән |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | муниципаль берәмлек бюджеты үтәлеше турындагы карарны бастырып чыгару | бастырылган<br>Әйе, бастырылган, әмма струтуралы рәвештә түгел<br>Юк, бастырылмаган | | төшенчә, аерым файлларда (таблицалар, кушымталар, карар тексты рәвешендә), барысының да тулы яки кыскача атамаларын күрсәтеп, мәгълүматлар урнаштыруны аңлата. |
| 1.4 | Хисап финанс елында муниципаль берәмлек бюджеты үтәлеше турындагы карар проекты материаллары составында муниципаль заданиеләрне үтәү турындагы мәгълүматларны бастырып чыгару | Әйе, бастырылган<br>Юк, бастырылмаган, яки әлеге пунктка искәрмәдә каралган таләпләргә җавап бирми | | Муниципаль заданиеләрне үтәү турындагы мәгълүматлар составында муниципаль хезмәт күрсәтүләр (эшләр) күләме һәм (яисә) сыйфаты турында күрсәткечләрнең планлы һәм факттагы зурлыклары мәҗбүри тәртиптә тапшырылырга тиеш |
| 1.5 | Агымдагы финанс елына һәм план чорына муниципаль берәмлек бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакында карарлар проектларын бастырып чыгару | Әйе, бастырылган<br>Юк, бастырылмаган | | Әгәр агымдагы финанс елына һәм план чорына муниципаль берәмлек бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакында карарлар проектларының кайберләре (алга таба - үзгәрешләр кертү турындагы карарлар проектлары) бастырылмаса, балл күрсәткече кимлек коэффициентына тапкырлана. Кимлек коэффициенты үзгәрешләр кертү турында бастырып чыгарылган карар проектларының үзгәрешләр кертү турында карар проектларының гомуми санына карата нисбәте буларак билгеләнә |
| 1.6 | Керемнәр буенча җирле бюджет үтәлеше турында актуаль мәгълүматларның булуы | Керемнәр буенча планлаштырылган күрсәткечләрдән тайпылу сәбәпләрен аңлатып, агымдагы финанс елында җирле бюджетның кварталлык үтәлеше турында мәгълүматлар | | Әгәр мәгълүматлар керемнәрнең төп төрләре (салым керемнәре, салым булмаган керемнәр, кире кайтарылмый торган кертемнәр) буенча планлаштырылган күрсәткечләрдән тайпылу |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | тапшырылды: кире кайтарылмый торган кертемнәр төрләре (дотацияләр, субсидияләр, субвенцияләр, башка бюджетара трансфертлар) ягыннан салым һәм салым булмаган керемнәр | | сәбәпләрен аңлатмыйча тапшырылса, балл күрсәткече 0,5 кимлек коэффициентына тапкырлана. |
| | | Мәгълүматлар бастырып чыгарылмаган яисә керемнәр статьялары буенча мәгълүматлар юк | | |
| 1.7 | Чыгымнар буенча җирле бюджет үтәлеше турында актуаль мәгълүматлар булу | Чыгымнарның функциональ классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча, планлаштырылган күрсәткечләрдән тайпылу сәбәпләрен аңлатып, агымдагы финанс елында җирле бюджетның кварталлык үтәлеше турында мәгълүматлар тапшырылган. | | Әгәр мәгълүматлар чыгымнарның функциональ классифи-кациясе бүлекләре буенча планлаштырылган күрсәткечләрдән тайпылу сәбәпләрен аңлатмыйча тапшырылса, балл күрсәткече 0,5 кимлек коэффициентына тапкырлана. |
| | | Мәгълүматлар бастырып чыгарылмаган яисә чыгымнарның функциональ классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча мәгълъматлар юк | | |
| 1.8 | Бурыч йөкләмәләре төрләре буенча муниципаль бурыч күләме турында актуаль мәгълүматларның булуы | Әйе, мәгълүматлар агымдагы финанс елында квартал саен бастырып чыгарыла | | |
| | | Әйе, мәгълүматлар агымдагы финанс елында ел саен бастырып чыгарыла | | |
| | | Юк, бастырылмаган | | |
| 1.9 | Чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль берәмлек бюджеты турында карар проектын бастырып чыгару | Әйе, бастырылган | | |
| | | Юк, бастырылмаган | | |
| 1.10 | Чираттагы финанс | Әйе, бастырылган | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | елына һәм план чорына муниципаль берәмлек бюджеты турында карарны бастырып чыгару | Юк, бастырылмаган | | |
| 1.11 | Җирле администрация тарафыннан расланган агымдагы финанс елының беренче кварталы, беренче яртыеллыгы, тугыз ае өчен муниципаль берәмлек бюджеты үтәлеше турында хисапны бастырып чыгару | Әйе, барлык хисап чоралы өчен бастырылган | | |
| | | Ике хисап чоры өчен бастырылган | | |
| | | Бер хисап чоры өчен бастырылган | | |
| | | Бк, бастырылмаган | | |
| 2. Кулланучыларның киң даирәсе өчен аңлаешлы формада төзелгән «Гражданнар өчен бюджет"ның булуы һәм эчтәлеге* | | | | |
| 2.1 | Бюджет процессы стадияләре буенча «Гражданнар өчен бюджет»ны интернет челтәрендә бастырып чыгару: чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль берәмлек бюджеты турындагы карар проекты, чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль берәмлек бюджеты турындагы карар, хисап финанс елына муниципаль берәмлек бюджеты үтәлеше турындагы карар буенча | Әйе, агымдагы финанс елында бюджет процессының барлык күрсәтелгән стадияләренә «Гражданнар өчен бюджетлар" төзелгән һәм бастырып чыгарылган | | «Гражданнар өчен бюджет" - муниципаль берәмлек бюджеты турында (бюджет үтәлеше турында) карарның (карар проектының) төп нигезләмәләренннән торган, кызыксынучы кулланучыларның киң даирәсе өчен аңлаешлы формада эшләнгән документ (брошюра, буклет, презентация) |
| | | Бюджет процессының ике стадиясенә «Гражданнар өчен бюджет" төзелгән һәм бастырып чыгарылган | | |
| | | Бюджет процессының бер стадиясенә «Гражданнар өчен бюджет" төзелгән һәм бастырып чыгарылган | | |
| | | Юк, агымдагы финанс елында «Гражданнар өчен бюджет" бастырып чыгарылган | | |
| 2.2 | «Гражданнар өчен бюджет»та кулланыла торган терминнар (глоссарийлар) аңлатмаларын бирү | Әйе, бирелгән | | |
| | | Юк, бирелмәгән | | |
| 2.3 | «Гражданнар өчен | Әйе, бирелгән | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | бюджет» та муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш фаразы күрсәткечләрен бирү | Юк, бирелмәгән | | |
| 2.4 | «Гражданнар өчен бюджет» та түбәндәге мәгълүмиатларны бирү: бюджет керемнәренең гомуми күләме, бюджет чыгымнарының гомуми күләме, бюджет дефициты/ профициты | Әйе, бирелгән | | |
| | | Юк, бирелмәгән | | |
| 2.5 | «Гражданнар өчен бюджет» та салым һәм салым булмаган керемнәр төрләре буенча бюджет керемнәре турында мәгълүматлар тапшыру | Әйе, бирелгән | | |
| | | Юк, бирелмәгән | | |
| 2.6 | «Гражданнар өчен бюджет»та бюджет чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бюджет чыгымнары турында мәгълүматлар | Әйе, бирелгән | | |
| | | Юк, бирелмәгән | | |
| 2.7 | «Гражданнар өчен бюджет»та бюджет турында күбрәк белергә теләгән гражданнар өчен элемтәгә керү өчен мәгълүматлар бирү | Әйе, бирелгән | | Күрсәткечне бәяләү максатында, «Гражданнар өчен бюджет" та турыдан-туры бирелгән элемтәгә керү өчен мәгълүматлар исәпкә алына |
| | | Юк, бирелмәгән | | |
| 3. Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре турында мәгълүматлар урнаштыру өчен Россия Федерациясенең рәсми сайтында (www.bus.gov.ru) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге муниципаль учреждениеләре тарафыннан мәгълүматларны бастырып чыгару | | | | |
| 3.1 | Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре турында мәгълүматлар урнаштыру өчен Россия Федерациясенең рәсми сайтында(www .bus.gov.ru) агымдагы финанс елына муниципаль заданиеләрне бастырып | 95% һәм күбрәк | | |
| | | 90% һәм күбрәк | | |
| | | 80% һәм күбрәк | | |
| | | 80%тан кимрәк | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | чыгарган муниципаль берәмлекнең муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләре өлеше (муниципаль заданиеләр җиткерелә торган муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләрнең гомуми саныннан), %ларда | | | |
| 3.2 | Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре турында мәгълүматлар урнаштыру өчен Россия Федерациясенең рәсми сайтында(www .bus.gov.ru) агымдагы финанс елына финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнарын бастырып чыгарган муниципаль берәмлекнең муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләре өлеше (муниципаль берәмлекнең муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләренең гомуми саныннан % ларда) | 95% һәм күбрәк | | |
| | | 90% һәм күбрәк | | |
| | | 80% һәм күбрәк | | |
| | | 80%тан кимрәк | | |
| 4. Финанс контролен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мәгълүматларны бастырып чыгару | | | | |
| 4.1 | Агымдагы финанс елына муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан контрольлек чаралар ы планнарын бастырып чыгару | Әйе, бастырылган | | Планда контрольлек объекты исеме, контрольлек чарасы исеме, контрольлек чарасын үткәрү сроклары, тикшерелә торган чор булырга тиеш |
| | | Юк, бастырылмаган | | |
| 4.2 | Агымдагы финанс елында муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән контрольлек чаралары | Әйе, бастырылган | | Мәгълүматларда контрольлек чарасы исеме, контрольлек чарасын уздыру өчен нигез, контрольлек объекты исеме, |
| | | Бастырылган, әмма тулы күләмендә түгел | | |
| | | Юк, бастырылмаган | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | турында мәгълүматларны бастырып чыгару | | | тикшерелгән чор, контрольлек чарасын уздыру сроклары, контрольлек чарасы барышында ачыкланган таләпләрне бозулар турында мәгълүматлар күрсәтелергә тиеш. |
| 4.3 | Чыгарылган танытмалар һәм күрсәтмәләр, шулай ук алар буенча кабул ителгән карарлар һәм чаралар турында, агымдагы финанс елында муниципаль финанс контроле органнары үткәргән һәр контроль чарасы нәтиҗәләре буенча мәгълүматларны бастырып чыгару | Әйе, бастырылган | | |
| | | Бастырылган, әмма тулы күләмендә түгел | | |
| | | Юк, бастырылмаган | | |
| 5. Бюджет процессында җәмәгатьчелек катнашуы | | | | |
| 5.1 | Бюджет тематикасы буенча җәмәгатьчелек фикерен белү өчен интернет аша сораштырулар үткәрү | Әйе, агымдагы финанс елында бюджет тематикасы буенча сораштырулар үткәрелде, агымдагы финанс елында сораштыру нәтиҗәләре бастырып чыгарылды | | Агымдагы елда бюджет тематикасы буенча сораштырулар яисә уздырылган сораштыру нәтиҗәләре, шулай ук агымдагы елда сораштырулар нәтиҗәләренең булуы бәяләнә |
| | | Әйе, агымдагы финанс елында бюджет тематикасы буенча сораштырулар үткәрелде, ләкин агымдагы финанс елында сораштыру нәтиҗәләре бастырып чыгарылмады | | |
| | | Юк, сораштырулар үткәрелмәгән яки мондый мөмкинлек юк | | |
| 5.2 | Гражданнар өчен бюджет тематикасы буенча электрон рәвештә сорау бирү, | Әйе, мондый мөмкинлек бар | | Сайтта бюджет тематикасы буенча сорау бирү, сорау, фикер һәм (яисә) тәкъдимне |
| | | Мондый мөмкинлек юк | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | бюджет тематикасы буенча фикер һәм (яисә) тәкъдим җибәрү мөмкинлеге булу | | | электрон рәвештә җибәрү – контекстлы меню аша (почта агентлары, өстәмә программалар ярдәменнән файдаланмыйча) – мөмкинлеге булу бәяләнә |
| 5.3 | Чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль берәмлек бюджеты турындагы карар проекты һәм (яисә) хисап финанс елына муниципаль берәмлек бюджеты үтәлеше турындагы карар проекты буенча уздырылган гавами тыңлаулар турында мәгълүматлар булу | Әйе, чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль берәмлек бюджеты турындагы карар проекты һәм (яисә) хисап финанс елына муниципаль берәмлек бюджеты үтәлеше турындагы карар проекты буенча уздырылган гавами тыңлаулар турында мәгълүматлар урнаштырылган | | |
| | | Әйе, чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль берәмлек бюджеты турындагы карар проекты һәм (яисә) хисап финанс елына муниципаль берәмлек бюджеты үтәлеше турындагы карар проекты буенча уздырылган гавами тыңлаулар турында мәгълүматлар урнаштырылган | | |
| | | Үткәрелгән гавами тыңлаулар турында мәгълүматлар юк | | |

*- 2.2 – 2.7 күрсәткечләре буенча мәгълүматлар агымдагы финанс елында эшләнгән һәм бастырып чыгарылган «Гражданнар өчен бюджет”ны бастыруның иң соңгы датасы буенча тапшырыла.